**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге**
**Советы**
**БАШЛЫГЫ**

**ул. Центральная, д.39, с. Чалпы, 423324**
**Азнакаевский район**
**Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**

**Үзәк урам, 39, Азнакай районы**
**Чалпы авылы, 423324**
**Тел. (8-5592) 35-5-46,**
**факс (8-5592) 35-5-46**
**Chal.Azn@tatar.ru**


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» ноябрь 2022 ел № 8

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чалпы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чалпы т. п., Центральная ур., 24 нче йорт адресы буенча урнашкан Чалпы авыл мәдәният йорты бинасында 2023 елның 08 декабрендә 10.00 сәгать 00 минутта Чалпы авылы Гагарин ур., 1 нче йорттан 33 нче йортка, Казанская ур., 1 нче йорттан 62 нче йортка, Ленин ур., 1 нче йорттан 131 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Чалпы торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының беренче этабын** билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Чалпы т. п., Центральная ур., 24 нче йорт адресы буенча урнашкан Чалпы авыл мәдәният йорты бинасында 2023 елның 08 декабрендә 13.00 сәгать 00 минутта Чалпы авылы Ленин ур. 132 нче йорттан 190 нчы йортка, Яшьләр ур., 1 нче йорттан 22 нче йортка, Яңа ур., 1 нче йорттан 5 нче йортка, Садовая ур., 1 нче йорттан 104 нче йортка, Центральная ур., 1 нче йорттан 29 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлегенең Чалпы торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча **гражданнар җыенының икенче этабын** билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300

сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Чалпы торак пунктында Яшьләр, Яңа, Гагарин, Казанская, Ленин, Садовая  урамнары буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (вак таш җәелгән юлларны карап тоту, юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Чалпы торак пунктында җирлекне яктырту  һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтү);

- Чалпы торак пунктында тракторчыга карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәт күрсәтүгә түләү (юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү);

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эш өчен түләү, триммер өчен ГСМ и запас частьләр сатып алу,  территорияләрне санитар чистарту буенча хезмәтләр, территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар уздыру );

- Чалпы торак пунктында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү «Җиңү көне», «Сабантуй»,"Халыкара өлкәннәр көне» нә  бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5.  Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы  __________  А.М.Мөхәмәтшин
(имза)  (имза расшифровкасы)